**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**Карары**

Уразай авылы № 29 01 июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыныц «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыныц Уразай авыл җирлеге Советы карары проектын кабул итәргә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, 2021 елныц 5 нче июненнэндэ соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakyevo.tatarstan.ru, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. 2020 елның 2 нче июль 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Энгельс урамы, 63 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советыныц «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.
4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм

искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Уразай авылы, Энгельс урамы, 65 йорт.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем төзергә

- Шәрифуллина А.М._ - Уразай авыл җирлеге башлыгы;

- Әхметшина Р.Б. - Уразай авыл җирлеге 5 нче округ депутаты;

- Зәкиев М.Э.- Уразай авыл җирлеге 4 нче округ депутаты.

6. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне, гражданнарны кабул итү, исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис : А.М.Шәрифуллина

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Уразай авыл җирлеге Советы
карарына 1 нче кушымта
«31» май 2021 № 28

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган (28.09.2012 №28, 05.08.2013 №44, 22.10.2014 №85, 30.09.2015 №6, 15.11.2016 №47, 17.04.2018 №94, 03.09.2018 №108, 05.11.2019 №155-17 , 17.11.2020 №12 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы " Уразай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертерегә:

1.1. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

1.2. 47 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзаң өстәргә:
« - алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru., Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.